КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 сентябрь г.Казань № 773

«Я.Е.Емельянов исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Я.Е.Емельянов исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстанның күпмилләтле халкының бердәмлеген саклау һәм ныгыту, керәшеннәрнең үз мәдәни-милли үзенчәлеген саклауга һәм үстерүгә, күптәнге мәдәни-тарихи яшәү мохитен яклауга, торгызуга һәм саклауга хокукларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтүне учреждение эшчәнлегенең төп максатлары итеп билгеләргә.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Учреждениенең иң чик штат саны 14 берәмлек тәшкил итә;

Учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсенең финанслар белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына:

Учреждениенең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

45 көн эчендә Учреждениенең уставын эшләргә һәм расларга һәм аны дәүләт теркәвенә алуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә;

Учреждение уставын раслаганнан соң 170 көн эчендә Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте, шул исәптән

Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

ел саен аның Уставында каралган эшчәнлекнең төп төрләре нигезендә Учреждение өчен дәүләт йөкләмәсен расларга.

5. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 180 көн эчендә Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы тарафыннан бирелгәнн исемлек нигезендә оештырыла торган Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт исемлеген оператив идарә хокукында Учреждениегә беркетергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән берлектә, бу карарның 4 нче һәм 5 нче пунктларында күрсәтелгән барлык чаралар үтәлгәннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 40 көн эчендә учреждениенең дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәт күрсәтүләргә) норматив чыгымнарын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин